ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53, с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин урамы, 53, Зирекле авылы,
423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, Zarek.Nsm@tatar.ru

КАРАР

КАРАР

2021 елның 27 июле

№ 11

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге территориясендә урнашкан: К-50 таулы нефть ятмасы скважиналары кустын төзекләндерү», линия объектына территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында»

«Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектларын тикшерүдә катнашу хокукын тәэмин итү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына таянып, ЗАО «Троицкнефть» 26.07.20021 елның 51 номерлы мөрәҗәгатен карап, Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты.

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында Зирекле авыл җирлеге территориясендә урнашкан «Таулы нефть ятмасы К-50 скважина кустын төзекләндерү» линияле объектка планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү 27 августа 2021 елда, 11.00 сәгатьтә Зирекле авыл клубы бинасында: Ленин урамы, 53 нче йорт, Зирекле авылы, Яңа Чишмә районы Татарстан Республикасы.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты халык алдында тыңлаулар үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Зирекле авылы, Ленин урамы, 53 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлегенең мәгълүмати стендында

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

Д.Г. Гайфетдинов